| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БОЛЬШЕПОЛЯНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗУР ПОЛЯНКА АВЫЛ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**11.11.2021** Зур Полянка ав. **№ 6**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлегенең Зур Полянка авылында гражданнар җыенын билгеләү турында» Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы карарын гамәлдән чыгару хакында**

«Татарстан Республикасында яңа коронавируслы инфекция таралуны булдырмау чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» 2021 елның 28 октябрендәге 1006 номерлы ТР МК карарын исәпкә алып, яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. «Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлегенең Зур Полянка авылында гражданнар җыенын билгеләү турында» 2021 елның 01 ноябрендәге 3 номерлы Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Зур Полянка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы** **М.Р. Афанасьева**